РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
5, Республика Татарстан, Сабинский
район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная,

тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикас
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп ура
12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
04.06.2021 г

КАРАР
№ 14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Мичән авыл җирлеге Советының 15.03.2013 елгы
10 номерлы карары белән расланган Мичән авыл
җирлегендә гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган
торак биналарны муниципаль милеккә тапшыру тәртибе
турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы акчаларын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 15.03.2013 елгы 10 номерлы «Гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны Мичән авыл җирлегенә муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турында" гы карары белән расланган Мичән авыл җирлеге Советы тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны гражданнар тарафыннан муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Хосусыйлаштырылган торак урыннарны Мичән авыл җирлеге муниципаль милкенә тапшырырга теләгән гражданнар, Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетына торак урынының барлык милекчеләре тарафыннан имзаланган, гражданның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар. Гаризага муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә торган документлар теркәлә.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес

буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/michan адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев